КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1582

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 935 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1339 нчы, 2023 ел, 11 ноябрь, 1464 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.18. Тиешле таләпләрне бозу куркынычы индикаторларының мәгънәсенә контроль объектының туры килүе планнан тыш контроль (күзәтчелек) чарасын урынга барып тикшерү яисә инспекция визиты рәвешендә уздыру өчен нигез булып тора. Мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 8 декабрь, 1582 нче
карары редакциясендә)

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына гражданнар мөрәҗәгатьләреннән, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларыннан даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршруты буенча расписаниедә каралган бер генә рейсның да рәттән өч көннән артык булуын үтәмәү турында мәгълүмат алу.

2. Юл-транспорт һәлакәтләре (аларның сәбәбе канәгатьләнерлек булмаган юл шартлары булган өч һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәтләре кылу) концентрацияләү урыннарын бер хисап елында юл эшләрен җитештерү участогында яисә юл сервисы объектын урнаштыру зонасында барлыкка килү.

---